**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422380 с. Федоровка, ул.Школьная, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФЕДОРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422380 Федоровка авылы, Школьная урамы, 1

тел. (84373) 5-70-15, факс 57-0-15; e-mail: Fedor@tatar.ru
ОГРН 1021606559875, ИНН/КПП 1638001688/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**24 .10. 2024** **№ 44-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 27-10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:
Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Федоровка авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 ел, № 27-10 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган сәүдә һәм административ-эшлекле үзәкләр (комплекслар) буенча 2025-2027 еллар күчеш чорына 1,2 процент, һәм алардагы биналар, 2028 елдан күрсәтелгән биналарда 2 процент ставкасы билгеләнә"

2. Әлеге карар үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Федоровка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**Җитәкче** **М.Ю. Никонорова**